| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 304

«Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы карарына (2021 елның 3 июнендәге 72 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

2009 елның 09 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы Федераль закон,2015 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламенты нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы карарына (2021 елның 3 июнендәге 72 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктында «муниципаль җирле үзидарә» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә» сүзләренә алмаштырырга;

2. 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү тәртибенә (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 03

июнендәге 72 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән)(1 нче кушымта) (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Тәртипнең 4.1.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Мәгълүматтан файдалану җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин ителә.»;

2.2.Тәртипнең 4.2 пунктының беренче абзацында «җирлек» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3.Тәртипнең 5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) массакүләм мәгълүмат чараларында Мәгълүматны халыкка җиткерү (бастырып чыгару);»;

2.4.Тәртипнең 6.1 пунктының 4 пунктчасында «җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар, күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары» сүзләренә алмаштырырга;

2.5.Тәртипнең 7.2 пунктында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

2.6.Тәртипнең 13.10 пунктында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

2.7. 16.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1. Җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле булган вазыйфаи затлар, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар, муниципаль хезмәткәрләр, ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.».

3. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы карарының (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 03 июнендәге 72 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) 2 нче кушымтасына (алга таба - 2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 2 нче кушымта исемендә «җирле үзидарә органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3.2. 2 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Рәсми сайтларда урнаштырыла торган «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм ведомство оешмалары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген раслау тәртибе 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ

номерлы Федераль закон (алга таба - 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнгән.»;

3.3. 2 нче кушымтаның 2 пунктында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

3.4. 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Ведомство оешмалары эшчәнлеге турында аларның рәсми сайтларында урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге, мондый оешмалар карамагында булган җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана»;

3.5. 2 нче кушымтаның 3 пунктында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәренең» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

4. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 03 июнендәге 72 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) 3 нче кушымтадагы «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. Кушымтаның исемендә «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәренең» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

4.2. «Мәгълүмат категориясе» графасында 5 нче юлны ««Интернет» челтәрендә ведомство буйсынуындагы оешмаларның рәсми битләре (булган очракта), рәсми сайтларның электрон адреслары һәм әлеге битләр күрсәткечләре турында мәгълүмат» сүзләре белән тулыландырырга;

4.3. I кисәк. Исемлекнең Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында гомуми мәгълүматны 5.1 - 5.3. түбәндәге эчтәлекле юллар белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 5.1 | «Интернет» челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми битләре (булган очракта) турында, әлеге битләр күрсәткечләре белән мәгълүмат ; | Актуаль хәлдә саклана |
| 5.2. | җирле үзидарә органы яки ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан гражданнарның (физик затларның) фикерен ачыклау белән бәйле сораштырулар һәм башка чаралар үткәрү турында мәгълүматны, җирле үзидарә органы тарафыннан гавами тыңлауга һәм (яки) җәмәгатьчелек фикер алышуына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материалларны, гавами тыңлаулар яки җәмәгатьчелек фикер алышулары нәтиҗәләрен, шулай ук гражданнар (физик | аны үткәрүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча |

| | | |
|---|---|---|
| 5.3. | затлар) үз тәкъдимнәрен электрон формада җибәрү ысуллары турында мәгълүматны ;<br>Бердәм порталдан файдаланып, җирле үзидарә органы үткәрә торган гавами тыңлаулар һәм җәмәгать фикер алышулары турында мәгълүматны; | аны үткәрүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча |

4.4. «Мәгълүмат категориясе» графасында 8 юлда «5 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

4.5.«Мәгълүмат категориясе» графасында 22 юлда «текстлар» сүзеннән соң «һәм (яисә) видеоязмалар» сүзләрен өстәргә;

4.6. Исемлекне түбәндәге эчтәлекле VIII - IX бүлекләр белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| VIII. «Рәсми битләрдә җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар урнаштыра торган мәгълүмат» | | |
| 48 | ведомство буйсынуындагы оешма турында гомуми мәгълүмат, шул исәптән:<br>а) ведомство буйсынуындагы оешманың исеме һәм структурасы, почта адресы, электрон почта адресы (булган очракта), белешмә хезмәтләренең телефон номерлары, шулай ук ведомство карамагындагы оешманың «Интернет» челтәрендәге рәсми бите булуы турында, әлеге битнең күрсәткече белән, мәгълүмат;<br>б) ведомство буйсынуындагы оешманың, аның структур бүлекчәләренең вәкаләтләре, бурычлары һәм функцияләре турында белешмәләр, шулай ук әлеге вәкаләтләрне, бурычларны һәм функцияләрне билгели торган законнар һәм башка норматив хокукый актлар исемлеге;<br>в) ведомство буйсынуындагы оешманың, аның структур бүлекчәләре җитәкчеләре турында белешмәләр(фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, шулай ук күрсәтелгән затлар ризалыгы белән алар турында башка белешмәләр) ;<br>2) башка мәгълүматны, шул исәптән, 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары һәм ведомство оешмалары эшчәнлеге турында. | Актуаль хәлдә саклана |
| Рәсми битләрдә җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан урнаштырыла торган мәгълүмат | | |
| 49 | 1) җирле үзидарә органы яисә ведомство буйсынуындагы оешма һәм аларның | Актуаль хәлдә саклана |

| | | |
|---|---|---|
| | эшчәнлеге турында мәгълүмат, шул исәптән җирле үзидарә органы яисә ведомство буйсынуындагы оешма исеме, почта адресы, электрон почта адресы, белешмә хезмәтләр телефон номерлары, җирле үзидарә органының рәсми сайты (булган очракта) яисә ведомство буйсынуындагы оешманың рәсми сайты турында мәгълүмат (булган очракта);<br>2) башка мәгълүматны, шул исәптән, 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары һәм ведомство оешмалары эшчәнлеге турында. | |

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**